**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1074**
**17.02.2023**

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының һәм җитәкчеләренең шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрү, коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә 2023 елның февралендә Яр Чаллы шәһәрендә «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының һәм җитәкчеләренең шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) конкурсның эксперт советы составын, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 60 000,00 (алтмыш мең) сум 00 тиен күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 17 февралендәге
1074 номерлы карарына
1 нче кушымта

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының һәм җитәкчеләренең шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының һәм җитәкчеләренең шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәренең актив яшь гражданнарын ачыклауга һәм бүләкләүгә, илне модернизацияләү процессына кушылган яшь гражданның позитив образын формалаштыруга һәм популярлаштыруга, гражданнар җәмгыяте институтларын үстерүгә, мәдәниятара диалог, шулай ук яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә булышлык итү һәм аларның казанышларын күрсәтүгә юнәлдерелгән.

2. Конкурсны гамәлгә куючы булып Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе тора. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

2 бүлек. Максатлар һәм бурычлар

3. Конкурсның максаты булып коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү һәм аларга булышлык итү, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрүдә ярдәм күрсәтү тора.

4. Бурычлар:

1) иҗтимагый хәрәкәт, яшьләр сәясәте, яшь гражданнарны тәрбияләүдә инновацион технологияләрне үстерү өчен шартлар тудыру;

2) балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең эшчәнлеген стимуллаштыру;

3) дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләрен популярлаштыру;

4) коммерцияле булмаган оешмаларның, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләрнең лидерларын һәм җитәкчеләрен дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашуга җәлеп итү.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста эшчәнлекләре Россия Федерациясе законнарына каршы килмәгән балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең һәм коммерцияле булмаган оешмаларның лидерлары һәм җитәкчеләре катнаша ала. Иҗтимагый берләшмәләрнең лидерлары һәм җитәкчеләре дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр булырга тиеш түгел.

6. Конкурс түбәндәге категория катнашучылар арасында үткәрелә:

- иҗтимагый берләшмә лидеры – катнашучы, иҗтимагый берләшмәнең төркем алдында торган бурычларны нәтиҗәле хәл итүче, башка катнашучыларның үз-үзләрен тотышларына әһәмиятле йогынты ясарга сәләтле вәкиле;

- иҗтимагый берләшмә җитәкчесе – оешманы гамәлгә куючы документлар нигезендә коллектив белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы зат.

7. Иҗтимагый берләшмәләр лидерларының һәм җитәкчеләренең 1 (бер) елдан да ким булмаган иҗтимагый эш стажы яки аларны конкурска җибәргән берләшмә эшчәнлегендә катнашу тәҗрибәләре булырга тиеш.

8. Иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеге Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килергә тиеш.

9. 2023 елда конкурсның номинацияләре:

1) балалар иҗтимагый берләшмәсе активисты (11-13 яшь);
2) яшьләр иҗтимагый берләшмәсе лидеры (14-15 яшь);
3) яшьләр иҗтимагый берләшмәсе лидеры (16-17 яшь);
4) яшьләр иҗтимагый берләшмәсе лидеры (18-30 яшь);
5) югары уку йорты/урта һөнәри уку йортының иҗтимагый берләшмәсе лидеры (18-25 яшь);
6) балалар/яшьләр иҗтимагый берләшмәсе җитәкчесе.

10. Бер балалар яки яшьләр иҗтимагый берләшмәсеннән катнашучылар саны чикләнмәгән.

## 4 бүлек. Үткәрү этаплары һәм сроклары

11. Конкурс этаплап үткәрелә:

I этап – читтән торып – 2023 елның 13 февраленнән 16 февраленә кадәр;
II этап – урында – 2023 елның 17 февраленнән 19 февраленә кадәр;
III этап – финал – 2023 елның 31 мартына кадәр.

12. Конкурста катнашу өчен заявкаларны кабул итү 2023 елның 16 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла. Заявка гугл-формада https://forms.gle/7TeQvnpqED7Nw7wN8 бирелә.

## 5 бүлек. Эксперт советы

13. Конкурсны үткәрү һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган, конкурсның эксперт советы төзелә.

14. Конкурсның эксперт советы:

1) конкурсның эчтәлеге, үткәрү тәртибе, конкурс программасы, катнашучылар составы, шул исәптән һәр номинациядә катнашучылар составы буенча оештыру комитетына тәкъдимнәр кертә;
2) катнашучыларны бәяләүне гамәлгә ашыра;
3) номинацияләрдә җиңүчеләр һәм призерлар, шул исәптән махсус номинациядә җиңүчеләр исемлеген формалаштыра;
4) читтән торып һәм урындагы этапларны үткәрү йомгаклары буенча һәр номинациядә махсус номинация билгели.

## 6 бүлек. Конкурсның программасы, бәяләү критерийлары

15. Конкурс үткәрү барлык этапларда да түбәндәгеләрне бәяләүне (0 дән 15 балга кадәр) күздә тота:

1) конкурста катнашучы турыдан-туры катнаша торган иҗтимагый берләшмә эшчәнлегенең технологияләре һәм методикасы, инновацион алымнары һәм ысуллары;
2) катнашучының оештыру, иҗади һәм коммуникатив сәләтләре;
3) катнашучының идарә итү сәләтләре, осталыгы һәм күнекмәләре;

4) конкурсантның белем дәрәҗәсе: хокук белемнәре, иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә якын килү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенең төп юнәлешләре, принциплары, механизмнары;

5) мәгълүмати культура.

Читтән торып һәм урындагы этапларның баллары кушыла.

16. Читтән торып үткәрелә торган этапның конкурс программасы конкурста катнашучының портфолиосын (папкасын) эксперт бәяләвен үз эченә ала, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) катнашучы тарафыннан ирекле формада әзерләнгән «Белемнәр. Казанышлар. Тәҗрибә» резюме (1 биттән артмаган күләмдә);

2) «Мин кемне укытучы-остаз дип атыйм» эссе;

3) иҗтимагый берләшмәнең конкурсант турыдан-туры тормышка ашыруда катнашкан социаль проекты (проект бер елдан да ким булмаган вакытта тормышка ашырылырга һәм аны тормышка ашыру турында хисап булырга тиеш);

4) конкурста катнашучының иҗтимагый эш тәҗрибәсен, аның уңышларын һәм казанышларын күрсәткән ирекле формадагы материаллар (фотоматериаллар, грамоталар, дипломнар һ. б.);

5) «Остаз – киләчәккә эшләүче һөнәр» фотокүргәзмәсе өчен материаллар (сез остаз дип санаган кеше фотосы, аның турында кыскача мәгълүмат).

17. Урындагы этапның конкурс программасы катнашучыларның түбәндәге сынауларда эксперт бәяләвеннән гыйбарәт:

1) сәхнәдә 3 минуттан да артмаган иҗади чыгышны күздә тоткан үз-үзеңне иҗади презентацияләү (чыгышның жанры – катнашучы тарафыннан сайлана);

2) тәкъдим ителгән иҗтимагый берләшмә эшчәнлегенең төп юнәлешләре кысаларында эшләнгән проектны яклау. Регламент 3 минуттан да артык түгел.

18. Конкурс программасының финалы: формат, тематика, эчтәлекне бирү оештыру комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә расланa һәм бу хакта чараны үткәргәнче кимендә 2 көн алдан конкурста катнашучыларга хәбәр ителә.

## 7 бүлек. Йомгак ясау

19. Конкурс сынауларында катнашу йомгаклары буенча әлеге нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән һәр номинациядә җиңүче, 2 призер һәм махсус номинациядә җиңүче билгеләнә.

20. Номинациядә җиңүче дип үз номинациясендә иң күп балл җыйган катнашучы танылa. Баллар саны тигез булган очракта, эксперт советы рәисе җиңүчене билгеләүдә хәлиткеч тавышка ия.

21. Конкурста җиңүчеләр конкурсны оештыручыларның һәм партнерларның дипломнары һәм призлары белән бүләкләнә.

22. Конкурста җиңүчеләр Казан шәһәрендә «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерларының һәм җитәкчеләренең республика конкурсында катнашуга тәкъдим ителәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева